КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 28 июль г.Казань № 725

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» 2021 ел, 30 декабрь, 1326 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» 2021 ел, 30 декабрь, 1326 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 1 июнь, 509 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

икенче абзацта «18 563 887,9 мең сум» сүзләрен «13 610 482,04626 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «604 201,5 мең сум күләмендә башка бюджетара трансфертлар рәвешендә федераль бюджеттан кергән» сүзләрен «3 604 201,5 мең сум күләмендә башка бюджетара трансфертлар рәвешендә федераль бюджеттан кергән» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «5 000 000,0 мең сум күләмендә субсидияләр рәвешендә федераль бюджеттан кергән акча һәм 3 333 333,4 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы» сүзләрен «10 000 000,0 мең сум күләмендә субсидияләр рәвешендә федераль бюджеттан кергән акча һәм 6 666 666,8 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацта «1 017 885,900 мең сум күләмендә башка бюджетара трансфертлар рәвешендә федераль бюджеттан кергән» сүзләрен «2 017 885,900 мең

сум күләмендә башка бюджетара трансфертлар рәвешендә федераль бюджеттан кергән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Юл эшләре программаларын финанслау дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесенә субсидия исәбеннән юл эшләрен башкару чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән 5 253 405,91374 мең сум күләмендәге программаны.»;

2 пунктта «46 804 252,62527 мең сум» сүзләрен «59 137 586,08527 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасын, «Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында Казан шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын, «Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында автомобиль юлларын һәм ясалма юл корылмаларын норматив хәлгә китерүгә юнәлдерелгән программаны, «Транспорт системасын үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Төбәк, муниципальара һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын үстерүгә ярдәм күрсәтү» федераль проекты чаралары кысаларында дәүләти-хосусый партнерлык механизмын кулланып гамәлгә ашырыла торган программаны, «Төбәк, муниципальара һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын үстерүгә ярдәм күрсәтү» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында төбәк яки муниципальара, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына карата юл эшчәнлегенә юнәлдерелгән программаны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә;

әлеге карарга «Юл эшләре программаларын финанслау дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесенә субсидия исәбеннән юл эшләрен башкару чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән программаны (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин